РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» 12 2018 г. №935

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы территориясендә 2018-2019 нчы

еллардагы Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен

үткәрү чорында янгын куркынычсызлыгын

тәэмин итү турында

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларында янгын куркынычсызлыгын, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген, физик һәм юридик затлар мөлкәтенең, дәүләти һәм муниципаль милекнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, 1994 елның 21 декабрендәге «Янгын куркынычсызлыгы турында»гы 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм 1993 елның 18 маендагы «Янгын куркынычсызлыгы турында»гы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Урнаштырырга:

2018 елның 20 декабреннән 2019 елның 10 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим;

янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда 1-3 класслы пиротехник эшләнмәләрне (бенгал утларыннан, хлопушкалардан тыш) куллануны түбәндәге чикләрдәге территорияләрдә тыюны билгеләргә:

Сәнәгать объектлары, транспорт инфраструктурасы, ягулык-энергетика комплексы чикләреннән 500 метр ераклыкта;

Торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары, кешеләр күпләп була торган объектлар чикләреннән 50 метр ераклыкта.

2. Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Баулы һәм Ютазы муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлегенең районара бүлегенә һәм Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Ютазы районындагы бүлегенә тәкъдим итәргә:

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын үткәрү урыннарын исәпкә алырга;

Кешеләр күп килә торган Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чаралары үткәрү урыннарын һәм объектларын профилактик карап чыгу үткәрергә;

Эчке эшләр министрлыгының Ютазы районы бүлеге хезмәткәрләре белән берлектә билгеләнмәгән сәүдә урыннарында пиротехник эшләнмәләрне, шулай ук Россия Федерациясе закончалыгы белән билгеләнгән тиешле сертификатлары булмаган продукцияне сатуны ачыклау һәм туктату буенча рейдлар оештырырга һәм үткәрергә;

пиротехник эшләнмәләрне кулланганда, оешмалар һәм гражданнар тарафыннан янгын куркынычсызлыгы чараларын, шул исәптән кертелгән тыюларның үтәлешен контрольдә тоту буенча чаралар уздыруда катнашырга.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

пиротехника әйберләрен таратканда һәм алардан файдаланганда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 22 декабрендәге «Пиротехника әйберләрен таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында"гы 1052 номерлы карары белән расланган янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә;

ирекле янгын сагы әгъзаларының янгын сүндерү техникасы һәм янгын сүндерү өчен яраклаштырылган техника белән тәүлек буе кизү торуын оештыру буенча чаралар комплексын тормышка ашырырга;

тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын тормышка ашырырга;

халыкка махсус җиһазландырылган мәйданчыклардан тыш пиротехник эшләнмәләрне кулланырга ярамавы турында игълан итәргә һәм куркынычсызлык таләпләрен үтәү буенча чаралар турында халыкка мәгълүмат җиткерү эшен оештырырга;

кирәк булган очракта, тиешле территорияләрдә пиротехника әйберләрен куллануны тыюны билгеләргә.

4. Урыссу бистәсе территориясендә пиротехник эшләнмәләрне куркынычсыз зонада - «Яңарыш» ял паркы артында, Аксакүл авылына таба «Урыссу-Каразирек» автоюлы артында куллану урынын оештырырга. Эшләтеп җибәрү мәйданчыгын, пиротехник эшләнмәләрне файдаланганда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүмат урнаштырылган стенд, тиешле күләмдә янгын сүндерү чаралары белән җиһазландырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче С. П. Самонина

А.Н. Захаров

2-81-49